# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

1 статья. «Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995 № 12; Республика Татарстан, 2000, 23 сентябрь, №192) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 3 статьяның 2 пунктында «дәүләт» сүзе алдыннан «ике» сүзен язарга, «телләрен» сүзен «телен дә» сүзләренә алмаштырырга.

2. 4 статьяда:
2 пунктны төшереп калдырырга;
3-5 пунктлар 2-4 пунктлар булалар.

3. 6 статьяның 2 пунктында:
«республиканың» сүзен төшереп калдырырга;
«көнен халыкка игълан иткәннән соң 7 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «билгеләнгән көннән соң 3 коннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга.

4. 7 статьяның 3 пунктында «, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. 12 статьяның 1 пунктында «җыелышларының» сүзеннән соң «,җирле үзидарәнең сайлаулы органнары» сүзләрен өстәргә.

6. 13 статьяның 1 пунктындагы беренче җөмләсенә «һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары тәкъдимнәре» сүзләрен өстәргә.

7. 15 статьяның 1 пунктындагы өченче абзацны «сайлаучыларның исемлеген төгәлләштерә,» сүзләреннән башларга.

8. 16 статьяда:

4 пунктта «бүтән» сүзен «югарырак яисә түбәнгерәк» сүзләренә алмаштырырга;

7 пункттагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

9 пунктка түбәндәге эчтәлектә җөмлә өстәргә:

«Әлеге таләпне шуңа вәкаләтле орган үтәмәгән очракта, югарырак сайлау комиссиясе, әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш, сайлау комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләп куя.»;

9. 17 статьяның 2 пунктына «, шулай ук федераль закон нигезендә Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләрен өстәргә.

10. 18 статьяда:

2 пунктта «матбугатта» сүзен «әлеге Законның 38 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чараларында шушы массакүләм мәгълүмат чараларын агымдагы бюджет финанславы акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта икенче җөмләдә «законнар» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

5 пункттагы икенче җөмләгә «Әлеге документ» сүзләреннән соң «шушы статьяның 4 пунктында күрсәтелгән чорда тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү эше башланганнан алып күрсәтелгән эш беткәнчегә кадәр участок сайлау комиссиясенә, территория һәм Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелергә мөмкин һәм» сүзләрен өстәргә.

11. 19 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлектә җөмлә өстәргә:

«Билгеләнгән составының кимендә өчтән икесе төзелгәч, сайлау комиссиясенең составы эшкә керешергә тулы хокуклы.».

12. 20 статьяда «Гамәлгә куючылары (гамәлгә куюда катнашучылары) дәүләт органнары яисә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары булган» сүзләрен «Әлеге Законның 38 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга.

13. 24 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Тавыш бирү көненә бер елдан да соңга калмыйча закон нигезендә төзелгән һәм теркәлгән сәяси иҗтимагый берләшмә (сәяси партия, башка төрле сәяси оешма, сәяси хәрәкәт) сайлау берләшмәсе була.».

14. 25 статьяга түбәндәге эчтәлектә 5 пункт өстәргә:

«5. Сайлау блогының исеме әлеге блокка кергән сайлау берләшмәләре вәкилләренең съездында (конференциясендә) билгеләнә. Сайлау блогының исемендә шушы яисә югарырак дәрәҗәдә теркәлгән һәм әлеге сайлау блогына сайлау берләшмәсе рәвешендә кермәгән сайлау берләшмәсенең исеме, шулай ук элегрәк теркәлгән бүтән сайлау блогының исеме кулланыла алмый. Сайлау блогы исемендә физик затның исемен һәм фамилиясен куллану бары тик шушы физик затның язма ризалыгы белән генә мөмкин була».

15. 26 статьяның 1 пунктында «,шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча да,» сүзләрен төшереп калдырырга.

16. 31 статьяның 8 пунктында:

«, сайлау берләшмәсе, сайлау блогы» сүзләрен төшереп калдырырга;

«төзи алалар» сүзләрен «төзи ала» сүзләренә алмаштырырга.

17. 32 статьяда:

1 пунктның беренче абзацында «кандидат үзе» сүзеннән соң «, аның вәкаләтле вәкиле» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Имзаларны тикшергәндә, моңа тикшерү өчен имзаларны сайлап алуны үткәрү дә керә, әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән затлар да катнашырга хокуклы.»;

13 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектә 15 пункт өстәргә:

«15. Мәҗбүр итәрлек хәлләр булмый торып, кандидат үзенең кандидатурасын кире алу нәтиҗәсендә йә әлеге Законның 35-41 статьяларында билгеләнгән нигезләмәләрне бозган өчен аны теркәү юкка чыгарылу нәтиҗәсендә әлеге статьяның 14 пунктында күрсәтелгән хәлләр килеп туганда, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча үзенең чыгымнарының тиешле өлешен кандидат исәбеннән ала».

18. 34 статьяда:

1 пунктта:

беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Теркәлгән кандидат эшләүче, хезмәт итүче предприятиенең, учреждениенең, оешманың администрациясе, хәрби частьнең командиры, эчке эшләр органы җитәкчесе кандидат теркәлгән көннән алып сайлауларның нәтиҗәләрен рәсми рәвештә бастырып чыгарган көнгә кадәр теркәлгән кандидатның гаризасы, рапорты буенча аны эшеннән, хезмәт

итүеннән бу чор эчендә теләсә кайсы көнне һәм теләсә нинди вакытка азат итәргә тиешләр»;

икенче җөмләдә «тиешле чорга» сүзләрен «бу очракта» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте нигезләре турында» Федераль закон нигезендә «А» категорияле дәүләт хезмәте урыннарын өстәмә рәвештә биләүче теркәлгән кандидатлар үзләренең хезмәт урыны өстенлекләреннән файдаланырга хокуксыз.

«Россия Федерациясенең дәүләт хезмәте нигезләре турында» Федераль закон нигезендә «А» категорияле дәүләт хезмәте урыннарын өстәмә рәвештә биләүче теркәлгән кандидатлар хезмәт вазыйфаларын үтәүдән азат булган вакытта гына сайлау алды агитациясен алып барырга хокуклы.».

19. 39 статьяда:

1 пунктта «, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына, сайлаучылар төркемнәренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының ышанычлы затлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 һәм 4 пунктларда «, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының вәкилләрен», «, сайлау берләшмәсенә, сайлау блогына» сүзләрен тиешле килешләрдә һәм саннарда төшереп калдырырга.

20. 40 статьяда:

1 пунктта «, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

21. 43 статьяда:

түбәндәге эчтәлектә яңа 8 пункт өстәргә:

«8. Гражданнар һәм юридик затлар кандидатны сайларга ярдәм итәрлек эшчәнлеккә финанс (матди) ярдәмен бары тик сайлау фонды аша гына күрсәтергә хокуклы. Сайлаулар белән турыдан-туры яисә читләтеп бәйле булган түләүле эшләр башкару, товарлар сату, түләүле хезмәт күрсәтүләр кандидатның, теркәлгән кандидатның, алар вәкаләт тапшырган затларның, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының мондый түләүле эш башкаруга, товарлар сатуга, түләүле хезмәт күрсәтүгә һәм алар өчен сайлау фондыннан түләүгә язма рәвештәге рөхсәтеннән башка тыела. Сайлаулар белән турыдан-туры яисә читләтеп бәйле булган эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне һәм товарлар сатуны юридик затлар, аларның филиаллары, вәкиллекләре һәм башка төрле бүлекчәләре тарафыннан бушлай башкару

яисә нигезсез төшерелгән бәяләргә башкару тыела. Сайлауларны әзерләү һәм үткәрү эшләрен, хезмәт күрсәтүләрне гражданның, өченче затларны җәлеп итмичә генә, үзе теләп бушлай шәхсән башкаруы рөхсәт ителә.»;

шуннан соңгы пунктларның нумерациясе үзгәрә;

11 пунктка түбәндәге эчтәлектә җөмлә өстәргә:

«Әгәр күрсәтелгән хокук бозулар сайлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгарганнан соң ачылса, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны сайлауны дөрес түгел дип тану хакында судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

22. 48 статьяда:

5 пунктның соңгы җөмләсендә:

«Бу чакта» сүзләреннән соң «сайлаучылар исемлегенә тиешле тамга салына һәм» сүзләрен өстәргә;

«әлеге сайлаулардагы тиешле участок сайлаучылары исемлегеннән төшереп калдырыла һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Кабат тавыш бирүне уздырган очракта, кабат тавыш бирү билгеләнгән көннән алып кабат тавыш бирү көне алдыннан сайлаучыларга Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башка урында тавыш бирү таныклыкларының ертып алынучы талоннары ертып алына һәм гамәлдән чыгарыла. Кабат тавыш бирү көнендә, тавыш бирү вакыты җиткәнче, башка урында тавыш бирүнең кулланылмаган таныклыклары ертып алынучы талоннары белән бергә гамәлдән чыгарыла. Тиешле территория яисә участок сайлау комиссиясе кулланылмаган ертып алынучы талоннарны һәм башка урында тавыш бирү таныклыкларын гамәлдән чыгару турында актлар төзи. Әгәр Татарстан Республикасы Президенты гомуми сайлаулар нәтиҗәсендә сайланган булса йә Татарстан Республикасы Президентын гомуми сайлаулар уздырылмаган яисә дөрес түгел дип танылган булса, башка урында тавыш бирүнең кулланылмаган таныклыклары, ертып алынучы талоннары белән бергә, гомуми сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң өченче көнне сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлдән чыгарыла.»;

9 пунктны төшереп калдырырга.

23. 49 статьяның 6 пунктында «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча гына» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән сайлаучылар саныннан өч проценттан да артмаучы микъдарда» сүзләрен өстәргә.

24. 50 статьяда:

4 пунктка түбәндәге эчтәлектә җөмләләр өстәргә:

«Һәр сайлаучы бер сайлау бюллетене алырга хокуклы. Әлеге статьяның 16 пунктында каралган очраклар искәрмә була. Сайлау бюллетене бирер алдыннан участок сайлау комиссиясе әгъзасы сайлаучыга башка урында тавыш бирү таныклыгы бирелмәгәнлекне, тавыш бирү бинасыннан читтә сайлаучыга тавыш бирү мөмкинлеге тудыру хакында сайлаучының гаризасы (мөрәҗәгате) әлеге статьяның 9 пунктында күрсәтелгән реестрда теркәлмәгәнлекне һәм тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне үткәрү өчен участок сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучыга җибәрелмәгәнлекне тагын бер кабат расларга тиеш. Әгәр сайлаучыга башка урында тавыш бирү таныклыгы бирелүе ачыкланса, мондый сайлаучы өстәмә рәвештә сайлаучылар исемлегенә кертелә, башка урында тавыш бирүнең ертып алынучы талоны аңардан алына, ә кабат тавыш бирү уздырылганда - башка урында тавыш бирү таныклыгы да алына. Сайлаучыдан алынган ертып алынучы талон һәм башка урында тавыш бирү таныклыгы гамәлдән чыгарылалар.»;

9 пунктка түбәндәге редакциядә беренче җөмлә өстәргә:

«Участок сайлау комиссиясе әлеге сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелгән һәм нигезле сәбәпләр белән (сәламәтлек торышы буенча, инвалидлык һәм башка сәбәпләр аркасында) тавыш бирү бинасына мөстәкыйль килә алмаган сайлаучыларга тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлектә 13 пункт өстәргә:

«13. Участок сайлау комиссиясе участок сайлау комиссиясе әгъзаларына читкә чыгып тавыш бирүне үткәрү өчен сайлау комиссиясенен тавыш бирү хокукы белән кимендә ике әгъзасына, төрле кандидатлар тарафыннан билгеләнгән тикшерүчеләргә тавыш бирү урынына килү өчен мөмкинлекләр булдырырга тиеш.»;

13-15 пунктларны 14-16 пунктлар дип санарга.

25. 51 статьяда:

2 пунктның д) пунктчасында:

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «15 юл. Башка урында тавыш бирүнең кулланылмаган таныклыклары саны (кабат тавыш бирү үткәргән очракта - башка урында тавыш бирүнең гамәлдән чыгарылган кулланылмаган таныклыклары саны);»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «16 юл. Башка урында тавыш бирү таныклыкларының әлеге Законның 50 статьясындагы 4 пункты нигезендә гамәлдән чыгарылган ертып алынучы талоннары саны (кабат тавыш бирүне үткәргән очракта - башка урында тавыш бирүнең әлеге Законның 50 статьясындагы 4 пункты нигезендә гамәлдән чыгарылган таныклыклары саны)».

26. 52 статьяда:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Башка урында тавыш бирү таныклыкларының ертып алынучы талоннары, ә кабат тавыш бирү үткәргән очракта башка урында тавыш бирүнең әлеге Законның 50 статьясындагы 4 пункты нигезендә гамәлдән чыгарылган таныклыклары санала, аларның саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 16 юлына кертелә. Гамәлдән чыгарылган ертып алынучы талоннар һәм башка урында тавыш бирү таныклыклары белән сайлау комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, чит ил (халыкара) күзәтүчеләре, сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары контроле астында, карап танышып чыгарга хокуклы.»;

31 пунктта «карарлары» сүзеннән соң «, участок сайлау комиссиясе төзегән актлар» сүзләрен өстәргә.

27. 53 статьяда:

5 пунктта:

беренче җөмләдә «беренче нөсхәсенә» сүзләреннән соң «территория сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

икенче җөмләдә «шикаятьләрнең» сүзе алдыннан «аерым фикерләрнең» сүзләрен өстәргә;

7 пунктны төшереп калдырырга;

8-9 пунктларны 7-8 пунктлар дип санарга, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Беркетмәнең икенче нөсхәсе һәм җыелма таблица участок сайлау комиссияләренең беркетмәләре, тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм беркетмәләр төзегәндә шунда булган шушы сайлау комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия һәм беркетмә төзегән әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затларның исемлекләре белән бергә, шулай ук әлеге Законда каралган башка документлар һәм комиссия мөһере белән бергә, сакланылучы бинада территория сайлау комиссиясе секретаренда комиссия эше беткәнче саклана̀лар.

8. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм җыелма таблицаның өченче нөсхәсе танышу һәм күчермәләрен алу өчен территория сайлау комиссиясе әгъзаларына һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә, әлеге законның 18 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән бүтән затларга бирелә.»;

10 пунктны 9 пункт дип санарга. Күрсәтелгән пунктның беренче җөмләсенә «закон таләпләрен үтәгән килеш» сүзләрен өстәргә.

28. 54 статьяда:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сайлауларның нәтиҗәләре турындагы гомуми белешмәләрне сайлаулар нәтиҗәләре мәгълүм булганнан соң бер тәүлек эчендә мәгълүмат чараларына җибәрә.»;

10 пунктта «бер ел буе саклана» сүзләре алдыннан «тавыш бирү йомгакларын һәм сайлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгарган көннән» сүзләрен өстәргә.

29. 60 статьяда:

2 пунктны төшереп калдырырга;

3 пунктны 2 пункт дип санарга.

30. Әлеге Законның 1 нче кушымтасында:

«сайлаучыларның инициатив төркеме тарафыннан ... күрсәтелүен хуплыйбыз» сүзләрен «үзен үзе (сайлаучы инициативасы, сайлаучылар төркеме) күрсәтү юлы белән ... күрсәтелүен хуплыйбыз» сүзләренә алмаштырырга;

«Сайлаучыларның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле» сүзләрен «Кандидатның (сайлаучының, сайлаучыларның инициатив төркеменең) вәкаләтле вәкиле» сүзләренә алмаштырырга».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 19 декабре
№ 495